ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» март 2020 ел № 99

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында Нигезләмәгә (яңа редакциядә) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклануны оештыру һәм туклану өчен түләү буенча акчасыз исәп-хисапка күчү турында» 2020 елның 11 мартындагы 85 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге 523 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында Нигезләмәгә (яңа редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гомуми белем бирү оешмаларында уку чорында кайнар иртәнге аш буларак кайнар аш тәкъдим ителә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучылары өчен бер укучыга бер көнгә 37 сум 70 тиен, шул исәптән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән субсидия 7 сум 70 тиен;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучылары өчен бер укучыга бер

көнгә 25 сум 80 тиен, шул исәптән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия 7 сум 70 тиен.

Янгында зыян күргән гаиләләрдәге балаларга соңиаль ярдәм чаралары соңиаль ярдәм күрсәтү чараларын күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итү елын да кертеп, ике уку елына түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү рәвешендә күрсәтелә.».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

3.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында Нигезләмәгә (яңа редакциядә) үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 16 гыйнварындагы 06 номерлы карары гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына, МБУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе»нә әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны гамәлдәге законнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**